Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең Югары Ушма авылында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

27 октябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23.1 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең Югары Ушма авылында гражданнар җыены карар итте:

1. Гражданнарның янга калдырылган үзара салым акчаларын 104226,75 (йөз дүрт мең ике йөз егерме алты) сум 75 тиен күләмендә:

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (һәлак булган сугышчыларга обелиск ясау һәм монтажлау, Югары Ушма авылы участогын төзекләндерү),

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар һәм спорт мәйданчыкларын һәм Югары Ушма авылындагы торак пункт территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү), торак пункт территориясен төзекләндерү эшләрен башкарганнан соң түбәндәге эшләрне башкаруга кулланырга:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Югары Ушма авылы Комаров урамындагы юлларны норматив хәлгә китерү).

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов